ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

13.11.2019 с. Русское Макулово 03

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 3 декабрендә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Татар Макылы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Татар Макылы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы:

**- Татар Макыл авылында зират коймалары;**
**- Татар Макыл зиратында хуҗалык блогы төзү;**
**- Татар Макыл зираты өчен хуҗалык җиһазлары сатып алу:**

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Татар Макылы авылы, Үзәк урам, 146 а йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасында 13.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Макыл авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге**
**Башлыгы** **А.И. Матвеева**